ГЛАВА НОВОРУССКО-МАМАТКОЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЯҢА РУС МӘМӘТХУҖАСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши, 422594

Красавин ур., 40 нче йорт, Яр Буе Моркваши авылы, 422594

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

23.10.2023 | с. Старое Русское Маматкозино | 01

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-

«Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегенең Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылына гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 маддәсе, 56 ст., “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 4 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегенең Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында гражданнардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2024 елда Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылы территориясендә яш урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

- материалларны сатып алып Яшьләр урамында суүткәргечне ремонтлау.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. «Осипов В.В.» шәхси эшмәкәр кибете янында: Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылы, Мәктәп урамы, 2 йорт адресы буенча 11.30 сәгатьтә гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге башлыгы В.В.Никитушкин